РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

«27» ноябрь 2018 № 794

Мәдәният учреждениеләре арасында ел саен Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан узучы бәйрәм чараларын үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау

2018 елның 20нче ноябрь 63нче номерлы район Башкарма комитеты мәдәният бүлеге җитәкчесе хатын карап, "Россия Федерациясе җирлеге үзидарәсенең гомуми принципларын оештыруы турында" 2003 елның 5 октяберендәгы 131нче номерлы Федераль закон нигезендә,

1. Кушымта нигезендә, Мәдәният учреждениеләре арасында ел саен Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан узучы бәйрәм чараларын үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау.

2. Теләче муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләре арасында Яңа 2018 елны каршы алу чараларын оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын 2нче кушымта нигезендә расларга.

3. Теләче муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләре арасында Яңа 2019 елны каршы алу чаралары конкурсы җюрие составын 3 нче кушымта нигезендә расларга

4. Күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенен социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хамидуллин

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
1нче номерлы кушымта
“27” ноябрь 2018 ел № 784

**Мәдәният учреждениеләре арасында ел саен Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан узучы бәйрәм чараларын үткәрү турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмә

Мәдәният учреждениеләре арасында Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан узучы бәйрәм чараларын үткәрү турында нигезләмә (алга таба - нигезләмә) Яңа Ел бәйрәмнәренең максатларын, бурычларын, шартларын һәм тәртибен регламентлый.

Район конкурсы бәйрәмнең килеп чыгу тарихы, атрибутлары, төрле илләрдә бәйрәм итү традицияләре белән танышу өчен үткәрелә.

Конкурсның максаты:

- район халкының ялын оештыру;
- яңа ел тематикасы мәдәни-массакүләм чараларның формаларын һәм төрләрен киңәйтү;
- мәдәният учреждениеләрен район халкын Яңа ел бизәлешенә җәлеп итү;
- районның эстетик яктан кызыклы яңа ел һәм Раштуа мохитен булдыру буенча иң яхшы оригиналь һәм сәнгатьчә бизәлешне ачыклау;
- яңа ел чараларында катнашучыларның сәнгати иҗатын үстерү.

## II. Конкурсны оештыручылар

Бәйгене Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге оештыра.

Бәйгене әзерләү һәм үткәрү буенча гомуми җитәкчелек Теләче муниципаль районы “Район мәдәният йорты” тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## III. Конкурсны оештыру комитетының һәм жюриның төп функцияләре

Конкурсның Оештыру комитеты:

- конкурс үткәрү турында хәбәр итә;
- конкурс үткәрү буенча жюри составын формалаштыра һәм раслый;
- конкурста җиңүчеләрне һәм катнашучыларны бүләкләүне оештыра.
- конкурсның Оештыру комитеты конкурс барышын гомуми контрольдә тота, кирәк булганда аңа төзәтмәләр кертә.

Конкурсның жюри составына Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге белгечләре керә.

Жюри:

- район конкурсы нәтиҗәләрен йомгаклау протоколы белән рәсмиләштерә.

## IV. Конкурсны үткәрү тәртибе

4.1. Конкурс 2018 елның 15 декабреннән 2019 елның 15 гыйнварына кадәр уздырыла.

1 нче этап:

- 2018 елның 20 декабренә кадәр мәдәният учреждениеләренең Яңа елга әзерлеге;

25 декабрьгә кадәр район мәдәният йорты төркеменең Вконтакте социаль челтәрендәге “Яңа ел һәм Раштуа бизәлешләре” альбомында биштән артык булмаган фото урнаштыру.

2 нче этап (читтән торып):

- 2018 елның 25 декабреннән 2019 елның 9 январенә кадәр: сайтта урнаштырылган конкурс материалларын карау һәм бәяләү.

3 нче этап (соңгы этап):

- 2019 елның 13 гыйнварында конкурска йомгак ясау.

4.2. Конкурс биш номинация буенча үткәрелә:

- “Иң матурЯңа ел чыршысы”;
- “Иң матур Яңа ел сәхнәсе»;
- “Әкият безгә кунакка килә» - мәдәният учреждениеләре янында ясалган кар сыннарына конкурс;
- “Иң үзенчәлекле Яңа ел концерты”;
- “Иң кызыклы Яңа ел сценариясе».

4.3. Мәдәният учреждениеләре бер номинациядә һәм шулай ук, берьюлы биш номинациядәдә катнаша ала.

4.4. Конкурс материаллары rdk_2001@mail.ru электрон адресына җибәрелә.

4.5. Смотр-конкурс нәтиҗәләре “Теләче” газетасында, район мәдәният йорты һәм Теләче муниципаль районы сайтында басылып чыгачак.

## V. Катнашучыларны бүләкләү

5.1. Йомгаклау беркетмәсе белән рәсмиләштерелгән жюри бәяләмәсе бүләкләү өчен нигез булып тора.

5.2. Шулай ук эшләрне сайлап алу процессында жюри тарафыннан билгеләнгән номинацияләрдә махсус бүләкләр дә булырга мөмкин. Конкурста җиңүчеләргә һәм номинантларга дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.3. Конкурста җиңүчеләр Теләче авылы үзәк паркында узачак “Искечә Яңа елны каршылау” бәйрәм чарасында бүләкләнәчәк.

## VI. Бәйгене финанслау

Финанслау район бюджеты һәм бюджеттан тыш җәлеп ителгән акчалар хисабына башкарыла.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2нче номерлы кушымта
“27” ноября 2018 ел № 794

Мәдәният учреждениеләре арасында ел саен Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан узучы бәйрәм чараларына багышланган конкурсның оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д.С. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе; |
| Нагимова Ф.М. | - | вакытлыча район мәдәният йорты директоры вазыйфаларын башкаручы; |
| Туктамышева А.Х. | - | район мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе; |
| Поташова А.Б. | - | район мәдәният йорты хормейстеры; |
| Ибрагимова З.В. | - | район мәдәният йорты методисты; |
| Романова С.В | - | район мәдәният йорты методисты; |
| Мингазов Р.И. | - | район мәдәният йорты культорганизаторы. |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
3нче номерлы кушымта
“27” ноябрь 2018 ел № 794

Җюри составы

Жюри председателе:

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д.С. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе; |

Члены жюри:

| | | |
|---|---|---|
| Нагимова Ф.М. | - | вакытлыча район мәдәният йорты директоры вазыйфаларын башкаручы; |
| Туктамышева А.Х. | - | район мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе; |
| Поташова А.Б. | - | район мәдәният йорты хормейстеры; |
| Ибрагимова З.В. | - | район мәдәният йорты методисты; |
| Романова С.В | - | район мәдәният йорты методисты. |